**СОВЕТ СТОЛБИЩЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422624 с.Столбище,
ул. Советская, д.103
тел: 4-12-91

**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СТОЛБИЩЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
422624 Столбище авылы,
Совет урамы, 103 нчы йорт,
тел: 4-12-91

**2022елның 25 августы** **16/1 номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең генераль планын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы, Столбище авыл җирлеге Уставы нигезендә,,Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең генераль планы проектына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 5 августындагы 10-53/9427 номерлы бәяләмәсен карап, 2022 елның 22 августындагы ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне карап тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең генераль планы проектын (1 нче кушымта)расларга.
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.
4. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2012 елның 21 августындагы 22/1 номерлы Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы карары әлеге карар үз көченә кергән мизгелдән үз көчен югалткан дип танырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе вазифаларын башкаручы И. Ф. Мөбәрәкшинга йөкләнә

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Столбище**
**авыл җирлеге Советы рәисе**
**вазыйфаларын башкаручы** **И.Ю.Романова**